ГЛАВА
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.12.2024 Баулы шәһәре №194

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы "Кырымсарай авылы җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проекты буенча иҗтимагый фикер алышуларны билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Баулы муниципаль район Советының 2018 елның 3 июлендәге 160 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар, (иҗтимагый фикер алышулар) үткәрү тәртибе турында Нигезләмәсе, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Уставының 17 статьясы нигезендә

КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының "Кырымсарай авылы җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проекты буенча иҗтимагый фикер алышуларны уздыруны билгеләргә (алга таба - Проект).

2. Проект буенча иҗтимагый фикер алышулар инициаторы – Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башлыгы.

3. Иҗтимагый фикер алышулар уздыру вакытын 2024 елның 28 декабреннән 10 гыйнварына кадәр билгеләргә.

4. Иҗтимагый фикер алышуларда каралачак Проект экспозициясен 2024 елның 28 декабрендә ачарга.

4.1. Экспозицияне уздыру урыны:

- Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Кырымсарай авылы җирлеге Башкарма комитеты бинасында Татарстан Республикасы, Баулы районы, Кырымсарай авылы, Совет урамы, 59А йорт адресы буенча;

- Баулы муниципаль районы сайтында www.bavly.tatarstan.ru «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә.

4.2. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Кырымсарай авылы җирлеге Башкарма комитеты бинасындагы экспозицияне барып карау режимы түбәндәге адрес буенча: Баулы муниципаль районы, Кырымсарай , Совет урамы, 59А йорт, эш көннәрендә Мәскәү вакыты буенча 8.30 - 11.30 һәм 13.30 - 16.00 сәгатькә кадәр.

5. Җәмәгать фикер алышуларында катнашучылар 2024 елның 28 декабреннән 10 гыйнварына кадәр, Мәскәү вакыты белән эш көннәрендә 8.30 дан 11.30 га кадәр, 13.30 дан 16.00 сәгатькә кадәр җәмәгать тыңлауларында каралырга тиешле проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм кисәтүләр кертергә хокуклы:

- иҗтимагый фикер алышулар оештыручыга, язма рәвештә, түбәндәге адрес буенча: Баулы шәһәре, Куйбышев урамы, 20 йорт, 101 каб;

- Bauly.arch@mail.ru электрон почтасы аша.

6. Иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы итеп, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитетын (алга таба - гавами тыңлауларны оештыручы) билгеләргә.

7. Гавами тыңлаулар оештыручыга:

7.1. Проектны карау буенча гавами тыңлаулар уздыруны тәэмин итәргә;

7.2. Проект буенча гавами тыңлаулар уздыру башлану турында хәбәр итүне, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль берәмлеге, Кырымсарай авылы җирлеге Башкарма комитеты бинасында мәгълүмат стендында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга;

7.3. Экспозицияләрне Татарстан Республикасы Баулы муниципаль берәмлеге, Кырымсарай авылы җирлеге Башкарма комитеты бинасында, 2024 елның 28 декабренннән 10 гыйнварына кадәр, эш көннәрендә, Мәскәү вакыты белән 8.30-11.30, 13.30-16.00 сәгатьләрдә, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Баулы муниципаль районы сайтында www.bavly.tatarstan.ru оештырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы
Башлыгы И.И. Гозәеров